РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ
ЧЕРЕМШАНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
ул. Советская, д.32, село Черемшан, 423100

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
Совет урамы, 32е йорт, Чирмешән авылы, 423100

тел./факс +7(84396) 2-59-00, email: cheremshan@tatar.ru, http://cheremshan.tatarstan.ru

30.09.2021 ел № 65

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы Советы
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасының «Чирмешән муниципаль районы» муниципаль берәмлегенә һәм Татарстан Республикасының Чирмешән муниципаль районы составына керүче муниципаль берәмлекләргә (авыл җирлекләренә) шәһәр төзелеше проектларының җирле нормативларын әзерләү, раслау һәм аларга үзгәрешләр кертү тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 29.4 статьясы нигезендә, шәһәр төзелеше проектлаштыруның җирле нормативларын раслауга бәйле мөнәсәбәтләрне җайга салу максатларында, Чирмешән районы прокурорының «Шәһәр төзелеше законнарын бозуларны бетерү турында» 2021 елның 9 августындагы 628-р номерлы күрсәтмәсен карап, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы «Чирмешән муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы составына керүче муниципаль берәмлекләрнең (авыл җирлекләренең) шәһәр төзелеше проектлауның җирле нормативларын әзерләү, раслау һәм аларга үзгәрешләр кертү тәртибен кушымта нигезендә расларга.

2. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советының 2018 елның 13 декабрендә кабул ителгән «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының шәһәр төзелеше проектлаштыруның җирле нормативларын әзерләү, раслау тәртибен раслау турында»гы 200 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитеты җитәкчесенә йөкләргә.

Муниципаль район башлыгы урынбасары,
Совет Рәисе урынбасары Г.М. Җамалетдинов

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советының 2021 елның 30 сентябрендәге 65 номерлы карарына кушымта

**Татарстан Республикасының «Чирмешән муниципаль районы» муниципаль берәмлегенә һәм Татарстан Республикасының Чирмешән муниципаль районы составына керүче муниципаль берәмлекләргә (авыл җирлекләре) шәһәр төзелеше проектларының җирле нормативларын әзерләү, раслау һәм аларга үзгәрешләр кертү тәртибе**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Тәртиптә Татарстан Республикасы «Чирмешән муниципаль районы» муниципаль берәмлегенә һәм Чирмешән муниципаль районы составына керүче муниципаль берәмлекләргә (авыл җирлекләре) шәһәр төзелеше проектлауның җирле нормативларын әзерләү, раслау һәм үзгәрешләр кертү тәртибе билгеләнә (алга таба – Район, авыл җирлекләре).

1.2. Районны, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының авыл җирлекләрен шәһәр төзелеше проектлаштыруның җирле нормативлары (алга таба - җирле нормативлар) районның, авыл җирлекләренең түбәндәге өлкәләргә караган җирле әһәмияттәге объектлар белән тәэмин ителешнең минималь рөхсәт ителгән дәрәҗәсе күрсәткечләре җыелмасын билгели: Район, авыл җирлекләрен электр- һәм газ белән тәэмин итү, муниципаль Район чикләрендәге торак пунктлардан читтә урнашкан автомобиль юллары, транспорт хезмәте күрсәтү, мәгариф, сәламәтлек саклау, мәгълүматлаштыру һәм элемтә, мәдәният һәм ял оештыру, социаль тәэминат һәм социаль яклау, физик культура һәм массакүләм спорт, көнкүреш һәм сәнәгать калдыкларын утильләштерү һәм эшкәртү, җәмәгать тәртибен саклауны тәэмин итү, районның, авыл җирлекләренең җирле әһәмияттәге мәсьәләләрен хәл итүгә бәйле башка өлкәләр һәм район, авыл җирлекләре халкы өчен мондый объектларның территориаль яктан мөмкин кадәр күбрәк файдалана алуының исәп-хисап күрсәткечләре.

1.3. Җирле нормативларда кеше тормышының уңай шартларын тәэмин итүнең минималь исәп-хисап күрсәткечләре Татарстан Республикасының шәһәр төзелешен проектлау нормативларындагы кеше тормышының уңай шартларын тәэмин итүнең исәп-хисап күрсәткечләренә караганда түбәнрәк була алмый.

## 2. Районның, авыл җирлекләренең шәһәр төзелеше проектларының җирле нормативларын әзерләү һәм раслау

2.1. Җирле нормативларны әзерләү Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты карары нигезендә башкарыла.

2.2. Җирле нормативлар проектын әзерләү турында карарда билгеләнә:

- җирле нормативлар проектын әзерләү өчен җаваплы зат;
- җирле нормативлар проектын әзерләү сроклары;
- кызыксынган затларның җирле нормативлар проекты буенча тәкъдимнәрен җибәрү һәм карау тәртибе;
- җирле нормативларны әзерләү буенча эшләрне оештыруның башка

мәсьәләләре.

Җирле нормативлар проектын әзерләү турындагы карар белән җирле нормативларны әзерләүгә техник бирем раслана.

2.3. Җирле нормативлар проектын әзерләү турындагы карар Чирмешән муниципаль районының «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырылырга һәм муниципаль хокукый актларны, башка рәсми мәгълүматны рәсми бастырып чыгару өчен билгеләнгән тәртиптә кабул ителгән көннән биш көн эчендә басылып чыгарга тиеш.

2.4. Җирле нормативларны әзерләү, җирле нормативларга үзгәрешләр кертү буенча тәкъдимнәрне Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, Чирмешән муниципаль районының җирле үзидарә органнары, физик һәм юридик затлар кертергә хокуклы.

2.5. Җирле нормативларны әзерләү, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, норматив техник документлар, Татарстан Республикасы шәһәр төзелешен проектлаштыруның республика нормативлары, Чирмешән муниципаль районының шәһәр төзелешен проектлаштыру нормативлары нигезендә тормышка ашырыла, түбәндәгеләрне исәпкә алып:

- муниципаль район территориясендә халыкның тыгызлыгы һәм социаль-демографик составы;

- муниципаль районның комплекслы социаль-икътисадый үсеше планнары һәм программалары;

- җирле үзидарә органнары һәм кызыксынган затлар тәкъдимнәре.

2.6. Җирле нормативлар проекты Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырылырга һәм муниципаль хокукый актларны, башка рәсми мәгълүматны рәсми бастырып чыгару өчен билгеләнгән тәртиптә, расланырга ике ай кала бастырылырга тиеш.

2.7. Кызыксынган затлар җирле нормативлар проекты буенча үз тәкъдимнәрен тәкъдим итәргә хокуклы.

2.8. Билгеләнгән тәртиптә әзерләнгән җирле нормативлар проекты Чирмешән муниципаль районы җирле үзидарә органнарының структур бүлекчәләре белән килештерелергә тиеш:

- Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы башкарма комитеты;

- Чирмешән муниципаль районы авыл җирлекләре башкарма комитетлары.

2.9. Җирле нормативлар проектын Чирмешән муниципаль районы җирле үзидарә органнарының структур бүлекчәләре, әлеге тәртипнең 2.8 өлешендә күрсәтелгән оешмалар һәм ведомстволар белән килештерү җирле нормативлар проектын килештерү өчен җибәргәннән соң бер ай эчендә гамәлгә ашырыла.

2.10. Җирле нормативлар проектын килештерү нәтиҗәләре Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан әзерләнгән проектның техник биремгә, норматив техник документларга, Татарстан Республикасы шәһәр төзелешен проектлаштыру буенча республика нормативларына, Чирмешән муниципаль районының шәһәр төзелешен проектлаштыру нормативларына туры килүе турында бәяләмәсе рәвешендә рәсмиләштерелә.

2.11. Башкарма комитет әлеге Нигезләмәнең 2.8 пунктында күрсәтелгән бәяләмә әзерләнгән көннән биш көн эчендә җирле нормативларның килештерелгән проектын Чирмешән муниципаль районы башлыгына җирле нормативлар проектын

Чирмешән муниципаль район Советы каравына кертү турында карар кабул итү өчен җибәрә.

2.12. Чирмешән муниципаль районы Советы җирле нормативлар проектын раслый. Раслау турындагы карар Чирмешән муниципаль районының рәсми порталында «Интернет» челтәрендә урнаштырылырга һәм муниципаль хокукый актларны, башка рәсми мәгълүматны рәсми бастырып чыгару өчен билгеләнгән тәртиптә аны кабул иткән көннән өч көн эчендә басылып чыгарга тиеш.

2.13. Җирле нормативларны раслау турында карар кабул ителгәннән соң биш көн эчендә Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты Чирмешән муниципаль районы составына керүче муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына аны тапшыруны тәэмин итә.

2.14. Җирле нормативларны раслау турында карар кабул ителгәннән соң биш көн эчендә Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты күрсәтелгән карарны, расланган җирле нормативларны кушып, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 29.1 статьясындагы 2 пункты нигезендә, төбәк әһәмиятендәге объектлар һәм җирле әһәмияттәге объектлар төрләре буенча шәһәр төзелеше проектлары нормативларын системалаштыруны тәэмин итү өчен, шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органына җибәрә.

2.15. Җирле нормативлар расланганнан соң шәһәр төзелеше проектлауның федераль яки региональ нормативлары, кешеләрнең тормышы һәм сәламәтлеге куркынычсызлыгын тәэмин итүгә, әйләнә-тирә мохитне саклауга, биналарның һәм корылмаларның ышанычлылыгына таләпләрне үзгәртә торган норматив хокукый актлар һәм кеше тормышының уңай шартларын тәэмин итүнең минималь исәп-хисап күрсәткечләрен билгеләүгә йогынты ясый торган башка таләпләр гамәлгә керсә, җирле нормативларга тиешле үзгәрешләр кертелә.

2.16. Шәһәр төзелеше проектының җирле нормативларына үзгәрешләр кертү шәһәр төзелеше проектлаштыруның җирле нормативларын әзерләү һәм раслау өчен әлеге тәртиптә билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

Район Советының
юридик бүлеге начальнигы Т.В. Рунова

Район Башкарма комитетының инфраструктура
үсеше бүлеге начальнигы –
районның баш архитекторы Х.С. Сәлахов